| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**3 октябрь 2023 ел** Күгеш авылы **№148**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе турында" 2019 елның 01 ноябрендәге 211 номерлы Күгеш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Күгеш авыл җирлеге Советының 2020 елның 13 ноябрендәге 13 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 31.07.2023 № 389-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымын түләү тәртибе турында» 2019 елның 01 ноябрендәге 211 номерлы Күгеш авыл җирлеге Советы карарына (Күгеш авыл җирлеге Советының 2020 елның 13 ноябрендәге 13 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта 1.1 нче пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1) торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яки) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3% шәхси торак

төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләреннән тыш;»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң бер ай узгач кына.

3. Әлеге карарны 2023 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (администрация бинасы) адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштырырга.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе:** **А. А. Гатауллин**